ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.02.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 305**

Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 апрелендәге «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 192 номерлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 7 июнендәге « Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында» 251 номерлы Карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 24 мартындагы «Татарстан Республикасында аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр-ташламалар бирү турында» 126 номерлы Карарына туры китереп, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен расларга (кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Зеленодольск муниципаль районы авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын билгеләү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 1310 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ ел саен, чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда, авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын финанслауны күздә тотарга.

4. Әлеге карарны ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З. Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җитәкче урынбасары (социаль мәсьәләләр, опека һәм попечительлек) Д. В.Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
карарына кушымта
16.02.2021 №305

Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Зеленодольск муниципаль районында авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү (алга таба - субсидияләр-ташламалар) буенча социаль ярдәм чараларын күрсәтү механизмын билгели.

2. Субсидия-ташламалар авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче Зеленодольск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре белгечләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) түбәндәге категорияләргә бирелә:

мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренә - торак, җылылык, ут өчен түләү, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы һәм коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары чикләрендә, чыгымнарының 100 проценты күләмендә. Социаль ярдәмнең күрсәтелгән чарасы шулай ук пенсиягә чыккан гражданнарга, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызларга), шулай ук "Иминият пенсияләре турында", "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" һәм "Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килүче гражданнарга, 2018 елның 31 декабренә торышы буенча, авыл җирлегендә яшәүче әлеге хезмәткәрләр арасыннан, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) һәм Зеленодольск муниципаль районы мәдәният учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгәннән чыгып бирелә;

3. Субсидияләр-ташламалар күләмен билгеләү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасында аерым категориядәге гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр-ташламалар бирү турында" 2006 елның 24 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Субсидия-ташламалар бирү турындагы Карар Зеленодольск муниципаль районындагы республика матди ярдәм үзәгенең (компенсация түләүләре) 21 нче бүлекчәсе (алга таба – РМЯҮ (КТ) бүлекчәсе) (РМЯҮ (КТ)

бүлекчәсе һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелгән килешү нигезендә) тарафыннан кабул ителә.

5. Субсидияләр-ташламалар әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарга, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган очракта бирелә.

6. Субсидия-ташламалар алу өчен мөрәҗәгать итүчеләр яисә аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затлар даими яшәү урыны буенча РМЯҮ (КТ) бүлекчәсенә түбәндәгеләрне тапшыралар:

1) субсидия-ташламалар билгеләү турында гариза;

2) эш урыныннан субсидия-ташламалар алу хокукы турында белешмә, әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча;

3) Мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затның ышанычнамә күчермәсе;

Мөрәҗәгать итүче яисә аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән зат, гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, паспортын (аны алмаштыручы документ), банкта ачылган шәхси счет реквизитларын күрсәтә.

Субсидия-ташламалар билгеләү өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Электрон документлар рәвешендә бирелә торган гаризалар һәм документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзаланалар һәм электрон чыганаклардан һәм (яисә) гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, тапшырыла.

Субсидия-ташламалар алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) тапшырганда, мөрәҗәгать итүче электрон документлар рәвешендә компенсация билгеләү өчен кирәкле максатларда һәм күләмдә, аның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалашуын белдерә.

"Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында", "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" һәм "Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүче, 2018 елның 31 декабренә торышы буенча, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән әлеге федераль законнарда каралган, 2018 елның 31 декабренә торышы буенча, пенсия билгеләү шартларына туры килү-килмәве турында белешмә тапшыралар.

7. Мөрәҗәгать итүченең субсидияләр-ташламалар алу хокукы турындагы белешмәләрнең дөреслеге өчен, закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) урнашкан муниципаль учреждениенең (алга таба - муниципаль учреждение), әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча субсидия-ташламалар алу хокукы турында белешмә биргән, вазыйфаи затлары җаваплы.

8. РМЯҮ (КТ) бүлекчәсе ведомствоара гарызнамәләре нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон рәвештә, вәкаләтле оешмалардан компенсация бирү турында карар кабул итү өчен түбәндәге кирәкле белешмәләрне ала:

гариза бирүченең гаилә составы турында;

мөрәҗәгать итүчегә пенсия билгеләү турында.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булу (булмау) турында.

9. Әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән тапшырылган документлар һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән белешмәләр нигезендә, РМЯҮ (КТ) бүлекчәсе, барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып эш көннәренә исәпләнә торган 10 көн эчендә, субсидия-ташламалар билгеләү турында, йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (язмача рәвештә почта адресы буенча, электрон документ рәвешендә электрон почта адресы буенча, телефонга смс-хәбәр белән, "Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы" Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинеты аша) мөрәҗәгать итүчегә җиткерә.

10. Субсидия-ташламалар билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүченең яисә аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затның әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмавы;

мөрәҗәгать итүченең яисә аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затның субсидия-ташламалар алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирүе.

11. Субсидия-ташламаларны билгеләү мөрәҗәгать итүченең яисә аның тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затның, әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырып, мөрәҗәгать иткән айдан гамәлгә ашырыла.

12. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль учреждениеләре, хисап аеннан соң килүче айның 2 сенә кадәр, субсидия-ташламалар алу хокукын югалткан гражданнар исемлекләрен, шул исәптән эштән китүгә бәйле рәвештә , РМЯҮ (КТ) бүлекчәсенә бирәләр.

13. Гражданинның торак урыннары һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча, соңгы өч елдан да артык вакыт өчен барлыкка килгән бурычлары булганда, законлы көченә кергән суд акты белән расланган очракта, субсидия-ташламалар бирү туктатыла.

14. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнарның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләре булганда, субсидияләр-ташламалар бирү, мондый бурычның барлыгы турында мәгълүмат кергән көннән, 90 көнгә туктатыла.

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча субсидияләр-ташламалар бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән , әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан җайга салынганнан соң, 90 көн эчендә субсидияләр-ташламалар бирү яңадан торгызыла.

Субсидия-ташламалар бирүне яңарту турында карар кабул иткәндә, ул шулай ук ташламалар бирү туктатылган айлар өчен дә түләнә.

15. Субсидияләр-ташламалар бирү, субсидияләр-ташламалар бирүне туктатуга китерә торган шартлар килеп чыккан айдан соң, киләсе айдан туктатыла.

16. Субсидияләр-ташламалар бирүне туктату өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан Зеленодольск муниципаль районының муниципаль учреждениесе белән әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән вазыйфалар категорияләре буенча хезмәт мөнәсәбәтләрен туктату, моңа шушы Тәртипнең 2 пункты нигезендә субсидия-ташлама бирелә торган очраклар керми;

мөрәҗәгать итүченең үлеме;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләргә субсидияләр-ташламалар бирүне туктатып тору турында хәбәр ителгән көннән алып 90 көн эчендә җайга салынмау.

Субсидия-ташламалар бирүне туктатып тору (яңарту), туктату турында карар субсидия-ташламалар бирүне туктатып торуга (яңартуга) китерә торган шартлар барлыкка килү турында ведомствоара бәйләнеш тәртибендә мәгълүмат алынганнан соң 10 эш көне эчендә кабул ителә, һәм гариза бирүче тарафыннан субсидия-ташламалар билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп), карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә алучыга җиткерелә.

17. Декрет ялында һәм бала карау буенча ялда булган мөрәҗәгать итүчеләр өчен субсидияләр-ташламалар саклана.

18. Социаль ярдәм чараларын бер үк вакытта берничә нигез буенча алуга хокукы булган гариза бирүчегә, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән башкасы билгеләнмәгән булса, социаль ярдәм чаралары мөрәҗәгать итүченең сайлавы буенча, аларның берсе буенча бирелә.

19. Субсидия-ташламалар РМЯҮ (КТ) бүлекчәсе тарафыннан мөрәҗәгать итүчеләргә булган яисә ачыла торган банк счетларына күчерү яисә мөрәҗәгать итүчегә почта элемтәсе аша яисә әлеге Тәртипнең 20 пунктында күрсәтелгән очракларда, башка ысул белән, яшәү урыны буенча илтеп җиткерү юлы белән түләнә. Субсидия-ташламалар алу ысулын сайлау мөрәҗәгать итүче тарафыннан субсидия-ташламалар алу срогына гамәлгә ашырыла һәм субсидия-ташламалар бирү турындагы гаризада күрсәтелә.

20. Субсидия-ташламаларны почта элемтәсе аша яисә башка ысул белән , сәламәтлеге, яше, җәяү яисә транспорт белән тәэмин ителеше аркасында банк

счетларыннан файдалану мөмкинлеге булмаган мөрәҗәгать итүчеләргә, яшәү урыны буенча илтеп җиткерү гамәлгә ашырыла.

21. Субсидияләр-ташламалар бирү белән бәйле чыгымнарны финанслау Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында
(шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче
һәм яшәүче гражданнарның аерым
категорияләренә торак һәм коммуналь
хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча
социаль ярдәм чараларын бирү тәртибенә
кушымта

Форма

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының
«Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда)
эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм
коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү
тәртибен раслау турында» ________ № ____ Карары нигезендә
субсидия-ташламалар алу хокукы турында

БЕЛЕШМӘ

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
(белешмә биргән учреждениенең исеме, аның почта адресы)

______________________________________________________________________________,
(белгечнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта күрсәтелә)

_______________________________________________ вазыйфасында эшләүче,
(кирәкмәгәнне сызарга)

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында» ________ № ____ Карары нигезендә, аның субсидияләр-ташламалар алу хокукына ия булуы турында белешмә бирелде.

Оешма җитәкчесе

_______________________

_______________________ (Ф. И. Ат.и. (соңгысы-булган очракта))
(имза)

М.У.